| | |
|---|---|
| ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24 октябрь 2022 ел № 6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылы өлешендә 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Мортыш Баш авылы, Мәктәп урамы, 4а йорты адресы буенча урнашкан МФЦ бинасында 2022 нче елның 2 нче ноябренә 15 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан кала, Илексаз авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2023 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Мортыш Баш авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонты, вак таш ташу);

2) Мортыш Баш авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

3) Мортыш Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар алу);

4) Мортыш Баш авылы зиратына инвентарь, техника өчен запас частьлар сатып алу;

5) янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар (мотопомпалар өчен запас частьләр) сатып алу;

6) Мортыш Баш авылы эчендәге юлларны кардан чистарту;

7) Мортыш Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Гыйльфанов Ф. М.